КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 28 март г.Казань № 300

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 декабрь, 1087 нче, 2011 ел, 29 июнь, 526 нчы, 2011 ел, 29 июль, 609 нчы, 2011 ел, 7 июль, 747 нче, 2012 ел, 27 апрель, 330 нчы, 2012 ел, 30 июнь, 567 нче, 2012 ел, 30 июль, 645 нче, 2012 ел, 27 октябрь, 908 нче, 2013 ел, 19 март, 186 нчы, 2013 ел, 29 апрель, 296 нчы, 2013 ел, 31 декабрь, 1111 нче, 2014 ел, 20 май, 332 нче, 2014 ел, 26 декабрь, 1039 нчы, 2015 ел, 10 март, 143 нче, 2016 ел, 26 февраль, 118 нче, 2016 ел, 26 декабрь, 996 нчы, 2017 ел, 18 май, 291 нче, 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы, 2018 ел, 23 апрель, 278 нче, 2018 ел, 24 июль, 586 нчы, 2018 ел, 17 декабрь, 1156 нчы, 2019 ел, 29 гыйнвар, 52 нче, 2019 ел, 23 май, 433 нче, 2019 ел, 13 июнь, 492 нче, 2019 ел, 11 сентябрь, 815 нче, 2019 ел, 21 сентябрь, 866 нчы, 2019 ел, 30 сентябрь, 883 нче, 2020 ел, 24 февраль, 132 нче, 2020 ел, 17 апрель, 300 нче, 2020 ел, 27 август, 747 нче, 2021 ел, 28 июнь, 509 нчы, 2021 ел, 25 август, 781 нче, 2021 ел, 23 декабрь, 1269 нчы, 2022 ел, 7 июнь, 534 нче, 2022 ел, 9 сентябрь, 970 нче, 2023 ел, 3 апрель, 396 нчы, 2023 ел, 27 июль, 897 нче, 2023 ел, 30 ноябрь, 1538 нче, 2024 ел, 13 март, 140 нчы, 2024 ел, 26 июнь, 468 нче, 2024 ел, 23 ноябрь, 1044 нче, 2025 ел, 29 май, 376 нчы, 2026 ел, 23 гыйнвар, 31 нче, 2026 ел, 28 февраль, 143 нче карарлары белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.5 пунктның 4.5.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«каты коммуналь калдыкларның органик өлешеннән ясалма грунтлар җитештерү юлы белән аларны утильләштерүгә тариф.»;

4.6 пунктның 4.6.6 пунктчасы үз көчен югалткан дип таныргa;

4.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.8.32 пунктча өстәргә:

«4.8.32. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, ведомство бүләкләрен гамәлгә куя һәм алар белән Дәүләт комитетының билгеләнгән өлкәдә эшчәнлек алып баручы хезмәткәрләрен, шулай ук башка затларны бүләкли.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин